ГЛАВА БАЛТАСИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«18» 03 2019 г. № 70

**Татарстан Республикасы Балтач район Советында гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау һәм гражданнарны шәхси кабул итүне тәэмин итү буенча эш Тәртибен раслау турында**

Гражданнар мөрәҗәгатьләрен "Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында" 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль закон, "Коррупциягә каршы көрәш турында" 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, "Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында" 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (2018 елның 14 маендагы 32-ТРЗ номерлы закон редакциясендә), "Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының шәхси кабул итүне тәэмин итү буенча бурычлары турында" 2006 елның 13 ноябрендәге 537 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының карары, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Уставы нигезендә, шулай ук җирле үзидарә органнарына тәкъдимнәр, гаризалар, шикаятьләр белән мөрәҗәгать итү буенча гражданнарның конституциячел хокукларын гамәлгә ашыру максатында Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы башлыгы **карар бирә**:

1. Татарстан Республикасы Балтач район Советында гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау һәм гражданнарны шәхси кабул итүне тәэмин итү буенча эш Тәртибен кушымтада бирелгәнчә расларга.

2. Айның һәр сишәмбесен 14-00 сәгатьтән 17-00 сәгатькә кадәр Татарстан Республикасы Балтач район Советында гражданнарны шәхси кабул итү көне итеп билгеләргә.

3. Балтач муниципаль районы башлыгы урынбасарына һәм Балтач район Советы Аппараты җитәкчесенә үзләренең компетенциясенә карап, Балтач район Советында гражданнарны шәхси кабул итүне тормышка ашыру һәм шулай ук җавап хатларына кул кую вәкаләтен бирергә.

4. Җаваплы итеп билгеләргә:

– Балтач район Советына почта элемтәсе аша, электрон документлар әйләнеше системасында, Балтач муниципаль районының Интернет - кабул итү бүлмәсе аша һәм «мөһим линия» телефоны буенча кабул ителгән язмача мөрәҗәгатьләрне үз вакытында теркәү өчен - җирле үзидарә органнары белән эшләү бүлегенең һәм оештыру бүлегенең әйдәп баручы белгечләрен;

– Балтач муниципаль районы башлыгы, аның урынбасары, район Советы Аппараты җитәкчесе тарафыннан гражданнарны шәхси кабул итүне оештыру, гражданнарның телдән мөрәҗәгатьләрен вакытында каралуын һәм үтәлешен контрольдә тоту өчен - җирле үзидарә органнары белән эшләү бүлеге башлыгын;

– гражданнарның язмача мөрәҗәгатьләрен һәм «мөһим линия» телефоны буенча кабул ителгән мөрәҗәгатьләрне вакытында карау һәм үтәүне тикшереп тору буенча - район Советы Аппараты җитәкчесен;

5.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

6.Үз көчен югалткан дип танырга:

Балтач муниципаль районы башлыгының “Балтач район Советында гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау буенча эш регламентын раслау турында” 2008 елның 27 декабрендәге 161 номерлы карарын;

Балтач муниципаль районы башлыгының “Россия Федерациясендә гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында” 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә “Гражданнарны шәхси кабул итүне оештыру турында” 2013 елның 25 сентябрендәге 126 номерлы карарын.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Балтач муниципаль<br>район башлыгы — Р.Р.Нотфуллин

Балтач муниципаль район башлыгының
2019 елның 18 нче мартыннан
70 нче номерлы карарына кушымта

**Татарстан Республикасы Балтач район Советында гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау һәм гражданнарны шәхси кабул итүне тәэмин итү буенча эш Тәртибе**

## 1. Гомуми нигезләмәләр.

1.1.Татарстан Республикасы Балтач район Советында Гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау һәм гражданнарны шәхси кабул итүне тәэмин итү буенча эшнең әлеге тәртибе (алга таба - Тәртип) «Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль закон(алга таба - 2006 елның 2 маендагы 59 - ФЗ номерлы федераль закон), «Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (2018 елны 14 маендагы 32-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Уставы нигезендә эшләнгән.

1.2. Әлеге Тәртип белән Россия Федерациясе гражданы (алга таба - шулай ук граждан) Россия Федерациясе Конституциясе, Татарстан Республикасы Конституциясе белән аңа беркетелгән җирле үзидарә органнарына мөрәҗәгать итү хокукын гамәлгә ашыру белән бәйле хокукый мөнәсәбәтләр җайга салына, шулай ук Татарстан Республикасы Балтач район Советының вазыйфаи затлары тарафыннан гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе билгеләнә (алга таба - район Советы).

## 2. Әлеге тәртиптә кулланыла торган төп төшенчәләр

2.1.Граждан мөрәҗәгате (алга таба - мөрәҗәгать) - җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка язма рәвештә яисә электрон документ рәвешендә тәкъдим, гариза яки шикаять, шулай ук гражданның дәүләт органына, җирле үзидарә органына телдән мөрәҗәгате.

2.2.Тәкъдим – гражданның законнарны һәм башка норматив хокукый актларны камилләштерү, җирле үзидарә органнары эшчәнлеген камилләштерү, иҗтимагый мөнәсәбәтләрне үстерү, дәүләт һәм җәмгыять эшчәнлегенең социаль-икътисадый һәм башка өлкәләрен яхшырту буенча тәкъдиме.

2.3.Гариза– гражданның аның конституциячел хокукларын һәм ирекләрен яисә башка затларның конституциячел хокукларын һәм ирекләрен гамәлгә ашыруда ярдәм итү турында үтенече, яисә законнарны һәм башка норматив хокукый актларны бозу, җирле үзидарә органнары һәм вазыйфаи затлар эшендә җитешсезлекләрне, яисә күрсәтелгән органнар һәм вазыйфаи затларның эшчәнлеген тәнкыйтьләү турында хәбәре.

2.4.Шикаять – гражданның аның бозылган хокукларын, ирекләрен яки законлы мәнфәгатьләрен яисә хокукларын, ирекләрен яки башка затларның законлы мәнфәгатьләрен торгызу яки яклау турында үтенече.

2.5.Вазыйфаи зат – вакытлыча яки аерым вәкаләт буенча хакимият вәкиле функцияләрен яисә җирле үзидарә органында оештыру-боеру, административ-хуҗалык функцияләрен башкаручы зат.

2.6.Коллектив мөрәҗәгать – ике яисә аннан да күбрәк гражданның мөрәҗәгате, гражданнар, шул исәптән юридик затлар берләшмәләренең мөрәҗәгате, шулай ук митингта яисә җыелышта катнашучылар тарафыннан тавыш бирү яисә имзалар җыю юлы белән кабул ителгән мөрәҗәгать аңлашыла.

2.7. Шәхси мәгълүматлар – билгеләнгән яки билгеләүче бер физик затка (шәхси мәгълүматлар субъектына) турыдан-туры яисә читләтеп кагылган теләсә нинди мәгълүмат.

2.8.Шәхси мәгълүматларны эшкәртү – автоматлаштыру чараларын кулланып, яки шундый чараларны кулланмыйча шәхси мәгълүматларны җыю, язу, системалаштыру, туплау, саклау, аныклау (яңарту, үзгәртү), тартып чыгару, куллану, тапшыру (тарату, бирү, керү), иясезләндерү, ябып кую, бетерү, юкка чыгару буенча башкарыла торган теләсә нинди гамәл(операция) яисә гамәлләр җыелмасы.

2.9.Шәхси мәгълүматларны тарату – билгесез затлар даирәсенә шәхси мәгълүматларны ачуга юнәлдерелгән гамәлләр.

2.10.Шәхси мәгълүматларны бирү – билгеле бер затка яки билгеле бер затлар даирәсенә шәхси мәгълүматларны ачуга юнәлдерелгән гамәлләр.

2.11.Шәхси мәгълүматларны ябып кую – шәхси мәгълүматларны эшкәртүне вакытлыча туктату (шәхси мәгълүматларны аныклау өчен кирәк булган очраклардан тыш).

2.12. Шәхси мәгълүматларны юк итү – шәхси мәгълүматларның мәгълүмат системасында шәхси мәгълүматлар эчтәлеген торгызу мөмкинлеген юкка чыгаручы һәм (яисә) нәтиҗәдә шәхси мәгълүматларның матди чыганакларын юк итүче гамәлләр.

2.13.Коррупциягә каршы көрәш – федераль дәүләт хакимияте органнары, Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, гражданлык җәмгыяте институтлары, оешмалар һәм физик затларның үзләренә билгеләнгән вәкаләтләр кысаларындагы эшчәнлеге:

а) коррупцияне кисәтү буенча, шул исәптән коррупция сәбәпләрен ачыклау һәм коррупцияне китереп чыгаручы сәбәпләрен бетерү буенча (коррупцияне булдырмау чарасын күрү);

б) коррупцион хокук бозуларны ачыклау, кисәтү, булдырмау, ачу һәм тикшерү буенча (коррупциягә каршы көрәш);

в) коррупциячел хокук бозулардан килеп килеп чыгучы нәтиҗәләрне минимальләштерү һәм (яисә) бетерү буенча.

2.14.Электрон документ әйләнешенең ведомствоара системасы –Татарстан Республикасында электрон документлар алмашуның, шулай ук Татарстан Республикасында электрон оештыру-боеру документларын булдыру, куллану, тапшыру һәм саклау буенча дәүләт мәгълүмат системасы.

## 3. Гражданнарның язма мөрәҗәгатьләре белән эшләү

3.1.Гражданнарның язма мөрәҗәгатьләре тәкъдимнәр, гаризалар һәм шикаятьләр рәвешендә килә.

Гражданның язма рәвештә бәян ителгән мөрәҗәгатендә мөрәҗәгать җибәрелә торган органның исеме яисә тиешле вазыйфаи затның фамилиясе, исеме, атасының исеме, яисә тиешле затның вазыйфасы, шулай ук тәкъдимнең, гаризаның яисә шикаятьнең асылын бәян итү, гражданның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта), җавап, мөрәҗәгатьне башка адреска юллау турындагы хәбәр җибәрелергә тиешле почта адресы яисә электрон почта адресы күрсәтелергә, шәхси имзасы һәм дата куелырга тиеш.

Кирәк булган очракта гражданин үзенең дәлилләрен раслау өчен язма мөрәҗәгатенә документлар һәм материаллар яки аларның күчермәләрен терки.

3.2. Гражданнар тәкъдимнәр, гаризалар, шикаятьләр белән Татарстан Республикасының дәүләт телләрендә, туган телендә яисә Россия Федерациясе халыкларының үзләре белгән теләсә кайсы башка телендә мөрәҗәгать итәргә хокуклы. Гражданнарның тәкъдимнәренә, гаризаларына, шикаятьләренә җаваплар мөрәҗәгать иткән телдә бирелә. Мөрәҗәгать иткән телдә җавап бирү мөмкинлеге булмаган очракта, Татарстан Республикасының дәүләт телләре файдаланыла.

3.3.Барлык язмача мөрәҗәгатьләр район Советына кергәннән соң өч көн эчендә теркәлә. Һәр мөрәҗәгатькә тәртип буенча теркәү номеры бирелә. Һәр яңа календарь елында яңа кергән мөрәҗәгатьләрнең нумерациясе беренче номердан башлана. Теркәлгәннән соң барлык кергән мөрәҗәгатьләрдә булган мәгълүматны алдан карау оештырыла. Әлеге процедураның максаты коррупция фактлары буенча гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләр санын билгеләү.

Кергән барлык мөрәҗәгатьләр арасыннан коррупцион хокук бозулар мөмкин булуы турында мәгълүматны үз эченә алганнары аерып алына (муниципаль хезмәткәрләрнең үзе яки өченче затлар өчен акча, кыйммәтләр, башка төр мөлкәт яки мөлкәти характердагы хезмәтләр рәвешендә файда алу максатларында гражданнарның законлы мәнфәгатьләренә карамастан үзенең вазыйфаи урынын законсыз файдалануы белән бәйле булган гамәлләрен (гамәл кылмауларын) күрсәтүче чын мәгълүматлар)

Әлеге процедура әлеге Тәртипнең 6 бүлегендәгечә аерым тәртиптә карала торган мөрәҗәгатьләрне ачыклау мөмкинлеге бирә.

3.4. Күтәрелгән мәсьәләләрне хәл итү район Советы компетенциясенә керми торган язмача мөрәҗәгать, теркәлгән көннән алып җиде көн эчендә,

мөрәҗәгатьне җибәргән гражданга мөрәҗәгатьне башка адреска юллау турында хәбәр итеп, мөрәҗәгатьтә күтәрелгән мәсьәләләрне хәл итү компетенциясенә керә торган тиешле органга яисә тиешле вазыйфаи затка җибәрелә, моңа әлеге Тәртипнең 3.14 пунктында күрсәтелгән очрак керми.

Шул ук вакытта хәбәрнамәнең текстында Федераль законның тиешле статьясына сылтама булырга тиеш. Белдерү кәгазенең икенче нөсхәсе эшкә теркәлә.

Язма мөрәҗәгатьтә куелган мәсьәләләрне хәл итү берничә дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары яисә вазыйфаи затлар компетенциясенә кергән очракта, теркәлгән көннән алып җиде көн эчендә, мөрәҗәгатьнең күчермәсе тиешле дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына яисә тиешле вазыйфаи затларга җибәрелә.

3.5.Карарына яисә гамәленә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелә торган органга яисә вазыйфаи затка шикаятьне карау өчен җибәрү тыела.

3.6. Язма мөрәҗәгатьләргә резолюцияләр кушылган хатның сул як югары почмагында яки гражданның язма мөрәҗәгатең беренче битендә рәсмиләштерелә. Резолюция вазыйфаи затның фамилиясен, исемен, атасының исемен, резолюция текстын (кирәк булганда - конкрет күрсәтмәләр һәм башкару датасы белән), имзасын һәм датаны үз эченә алырга тиеш.

3.7. Әгәр район башлыгы, аның урынбасары, район Советы Аппараты җитәкчесе резолюциясендә берничә башкаручы күрсәтелсә, язма мөрәҗәгатьтә куелган барлык мәсьәләләрне үтәү өчен җаваплы булып беренче күрсәтелгән башкаручы тора.

3.8. Район Советына кәгазьдә кергән язма мөрәҗәгатьләр мәҗбүри рәвештә электрон документлар әйләнеше системасына куела.

3.9.Район Советына яки вазыйфаи затка үз компетенцияләре буенча кергән язмача мөрәҗәгатьләр теркәлгән көннән алып 30 көн эчендә карала.

3.10. Район Советына кергән мөрәҗәгатьләрне теркәү көне аларны карау срогының башы булып санала.

Мөрәҗәгать авторына җавап имзасы датасы мөрәҗәгатьләрне карау тәмамлану срогы дип санала.

3.11.Язма мөрәҗәгатькә җавап Балтач муниципаль районы башлыгы бланкында әзерләнә һәм район башлыгы тарафыннан имзалана, үз компетенциясе буенча район башлыгы урынбасарына кергән язмача мөрәҗәгатькә җавап Балтач район Советы бланкында әзерләнә һәм район башлыгы урынбасары тарафынанн имзалана. Җавап граждан күрсәткән адреска җибәрелә.

3.12. Ике һәм аннан күбрәк затның мөрәҗәгатенә (күмәк мөрәҗәгать) җавап мөрәҗәгатьтә җавап җибәрелә торган затка яисә мөрәҗәгатькә имза салган гражданнар коллективы вәкиле буларак күрсәтелгән затка җибәрелә.
Күмәк мөрәҗәгатьтә җавап җибәрелергә тиешле зат билгеләнмәгән булса, җавап мөрәҗәгать итүчеләр (имза салучылар) исемлегендә үз почта адресын яисә электрон почта адресын күрсәткән беренче гражданга җибәрелә.

Күмәк мөрәҗәгатькә җавап җибәрү турында үтенеч мөрәҗәгать итүче (имза салучы) затларның берничәсе тарафыннан белдерелгән очракта, җавапның

күчермәсе үзләре күрсәткән адреслар, электрон почта адреслары буенча аларның һәрберсенә җибәрелә.

3.13. Гражданшикаятендә күрсәтелгән мәгълүматлар ахыргы карарны чыгару өчен җитәрлек түгел икән, гамәленә карата **дәгъва** белдерелә торган учреждениедән яки заттан кабул ителгән карарның нигезле булуы турында бәяләмә белән тикшерү материаллары соратып алына. Кирәк булган очракта, район башлыгы күрсәтмәсе буенча шикаятьне урынга барып тикшерү өчен район Советы аппараты хезмәткәрләре командировкага җибәрелә ала.

3.14. Язмача мөрәҗәгать тексты укырлык булмаган очракта, мөрәҗәгатькә җавап бирелми һәм ул карау өчен тиешле компетенциясе булган органга яисә вазыйфаи затка җибәрелми, бу хакта мөрәҗәгатьне җибәргән гражданга, әгәр аның фамилиясе һәм җавап җибәрелергә тиешле адрес укырлык булса, мөрәҗәгатьне теркәгән көннән алып җиде көн эчендә хәбәр ителә.

Язмача мөрәҗәгать тексты тәкъдимнең, гаризаның яисә шикаятьнең асылын ачыкларга мөмкинлек бирмәгән очракта, мөрәҗәгатькә җавап бирелми һәм ул карау өчен тиешле компетенциясе булган органга яисә вазыйфаи затка җибәрелми, бу хакта мөрәҗәгатьне җибәргән гражданга мөрәҗәгатьне теркәгән көннән алып җиде көн эчендә хәбәр ителә.

3.15. Язмача мөрәҗәгатьтә аны җибәргән гражданның фамилиясе яисә җавап җибәрелергә тиешле адрес (почта адресы яисә электрон почта адресы) күрсәтелмәгән очракта, мөрәҗәгатькә җавап бирелми. Әгәр күрсәтелгән мөрәҗәгатьтә хокукка каршы әзерләнә, кылына яисә кылынган гамәл турында, шулай ук аны әзерләүче, кылучы яисә кылган зат турында белешмәләр булса, мөрәҗәгать тиешле компетенциясе булган дәүләт органына җибәрелергә тиеш.

3.16. Әгәр гражданның язмача мөрәҗәгате район Советына яисә бер үк вазыйфаи затка берничә тапкыр җибәрелгән булса, элек җибәрелгән мөрәҗәгатьләргә бәйле рәвештә асылда берничә тапкыр язма җаваплар бирелгән мәсьәлә булып, шул ук вакытта мөрәҗәгатьтә яңа дәлилләр яки шартлар күрсәтелмәсә, район Советының вазыйфаи заты чираттагы мөрәҗәгатьнең нигезсез булуы һәм әлеге мәсьәлә буенча граждан белән язышуны туктату турында карар кабул итәргә хокуклы. Әлеге карар турында мөрәҗәгать җибәргән гражданга хәбәр бирелә.

3.17.Мөрәҗәгатькә әзерләнгән җавап проектының сул яктан түбән почмагында башкаручы үзенең тамгасын сала һәм компетенциясенә туры китереп Балтач муниципаль районы башлыгына, аның урынбасарына, район Советы аппараты җитәкчесенә, имза куярга тапшырыла.

3.18. Әгәр мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән барлык мәсьәләләр карап тикшерелгән, алар буенча тиешле чаралар күрелгән һәм гамәлдәге законнарга туры китереп тулы җавап бирелгән булса гражданнарның язмача мөрәҗәгатьләре хәл ителгән дип санала.

## 4.Гражданнарны шәхси кабул итүне оештыру

4.1. Район Советында гражданнарны шәхси кабул итү үткәрелә:

Балтач муниципаль районы башлыгы тарафыннан;

Балтач муниципаль районы башлыгы урынбасары тарафыннан;

Балтач район Советы Аппараты җитәкчесе тарафыннан.

4.2.Гражданнарны шәхси кабул итүне оештырганда гражданнарны шәхси кабул итү тәртибенә карата "Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында" 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән таләпләр исәпкә алына.

4.3.Кабул итү көннәре һәм сәгатьләре, гражданнарны кабул итүне әзерләү өчен җаваплы вазыйфаи затларның контакт телефоннары турында мәгълүмат массакүләм мәгълүмат чаралары аша гражданнарга җиткерелә һәм Балтач муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырыла, шулай ук урыннарда халык белән очрашуларда җиткерелә. Әлеге мәгълүмат шулай ук ТР. Балтач муниципаль районы, Балтач ш.т.п., Ленин ур., 42 йорт адресы буенча урнашкан ТР Балтач районы башкарма комитеты бинасының 1 нче катындагы мәгълүмат такталарында урнаштырыла.

4.4.Муниципаль район башлыгының гражданнарны шәхси кабул итүенә алдан язылу җирле үзидарә органнары белән эшләү бүлеге башлыгы тарафыннан әлеге Тәртипкә 1 нче кушымта итеп теркәлгән кушымта формасындагы журналда алып барыла.

4.5.Гражданнарны кабул итүне теркәү һәм исәпкә алу гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү буенча җаваплы вазыйфаи зат тарафыннан, гражданнарны кабул итүне исәпкә алу журналында вазыйфаи бурычлар нигезендә алып барыла (2 нче кушымта). Телдән мөрәҗәгатьләрнең эчтәлеге гражданны шәхси кабул итү карточкасына (3 нче кушымта) кертелә, ул үз эченә гражданны кабул итү датасы, аның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (соңгысы булган очракта), аның яшәү урыны адресы, кабул итүне алып баручы вазыйфаи (вәкаләтле) затның фамилиясе, телдән мөрәҗәгать эчтәлеге һәм аның буенча күрелгән чаралар турында мәгълүматны алырга тиеш. Күрсәтелгән реквизитлар башка кирәкле белешмәләр белән тулыландырылырга мөмкин. Шәхси кабул итү нәтиҗәләре буенча бирелгән күрсәтмәләр һәм йөкләмәләр белән шәхси кабул итү карточкасы башкаручыларга кабул итү көнендә имзаланып бирелә һәм контрольгә куела.

Гражданнарны шәхси кабул итү карточкалары ведомствоара электрон документлар әйләнеше системасында(алга таба ВЭДӘС) теркәлә. Шәхси кабул итү вакытында граждан язмача гариза бирсә, әлеге мөрәҗәгать шулай ук ВЭДӘСда гражданнарны шәхси кабул итү карточкасыннан аерым теркәлә. Әлеге мөрәҗәгать 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгәнчә һәм әлеге Тәртиптә карала.

4.6. Шәхси кабул итү вакытында граждан үзенең шәхесен раслаучы документ күрсәтә.

4.7. Кабул итүне гамәлгә ашыручы вазыйфаи (яки вәкаләтле) зат гражданны игътибар белән тыңларга һәм аның мөрәҗәгатенең асылына җентекләп төшенергә тиеш. Шәхси кабул итү вакытында телдән бәян ителгән мөрәҗәгатьтәге фактларның һәм хәлләрнең булуы бәхәссез булса һәм аларны өстәмә тикшерү таләп ителмәсә, җавап, гражданның ризалыгы белән, кабул иткән зат тарафыннан телдән бирелергә мөмкин, бу хакта шәхси кабул итү

карточкасына язып куела, ул мөрәҗәгать итүченең шәхси имзасы белән раслана.

Калган очракларда мөрәҗәгатьтә куелган мәсьәләләрнең асылы буенча язмача җавап бирелә.

4.8.Мөрәҗәгатьтә Татарстан Республикасы Балтач район Советы компетенциясенә керми торган мәсьәләләр булса, гражданга кая һәм нинди тәртиптә мөрәҗәгать итәргә кирәклеге турында аңлатма бирелә.

4.9. Әгәр гражданга мөрәҗәгатьтә куелган мәсьәләләрнең асылы буенча элек җавап бирелгән булса шәхси кабул итү барышында алга таба бу мөрәҗәгатьне карамаска мөмкин.

4.10.Мөрәҗәгатьне алга таба карау һәм язмача җавап әзерләү тәртибе турында гражданга кабул итү вакытында телдән хәбәр ителә.

4.11. Вазыйфаи затлар гражданнарны шәхси кабул итүгә бәйле мәсьәләләр буенча башка җирле үзидарә органнарының предприятиеләрнең, учреждениеләрнең яки оешмаларның кирәкле белешмә һәм мәгълүмат материалларын (норматив хокукый актлар нигезендә игълан ителергә тиеш булмаган мәгълүматлардан тыш) тапшырырга, квалификацияле консультацияләр, элемтә белән тәэмин итү, хезмәткәрләрне кабул итү өчен җибәрү һәм башкалар өчен җаваплы җитәкчеләренә һәм хезмәткәрләренә мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

4.12. Әгәр граждан кабул иткәндә әйләнә-тирәдәгеләрнең тормышы һәм сәламәтлеге өчен турыдан-туры янаучы гамәлләр кыла икән, кабул итүне алып баручы вазыйфаи (яки вәкаләтле) зат Россия Федерациясе законнары нигезендә тиешле чаралар күрә. Кирәк булганда эчке эшләр органнары һәм ашыгыч медицина ярдәме хезмәткәрләре чакырыла.

4.13. Район Советында гражданнарны шәхси кабул итү өчен билгеләнгән көннәрдә һәм сәгатьләрдә беренче чиратта шәхси кабул ителү хокукына түбәндәгеләр ия:

- I, II төркем инвалидлары һәм (яисә) аларның законлы вәкилләре (ата-ананың берсе, уллыкка (кызлыкка) алучылар, опекун яисә попечитель);

- Бөек Ватан сугышы ветераннары, Россия Федерациясе Геройлары, Советлар Союзы Геройлары, Дан орденының тулы кавалерлары, Социалистик Хезмәт Геройлары, Россия Федерациясе Хезмәт Геройлары; хәрби гамәлләр ветераннары;

- инвалид балалар, ятим балалар, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затлар, шулай ук аларның законлы вәкилләре һәм вәкилләре, әгәр алар мондый балаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итүгә һәм яклауга бәйле мәсьәләләр буенча мөрәҗәгать итсәләр;

- кабул итүгә өч яше тулмаган балалар белән килгән гражданнар.

4.14. 4.13 пунктында күрсәтелгән гражданнар шәхси кабул ителгәндә үзләренең шәхси беренче чиратта кабул ителү хокукларын раслый торган документны күрсәтәләр.

4.15. Шәхси беренче чиратта кабул ителү хокукына берьюлы берничә граждан ия булган очракта, күрсәтелгән гражданнарны кабул итү аларның шәхси кабул итүгә килүе тәртибендә гамәлгә ашырыла.

## 5."Турыдан-туры элемтәләр" һәм "мөһим элемтәләр" телефоннары буенча кабул ителгән гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау"

5.1. Район Советында үз эшчәнлеге турында гражданнарның мәгълүмат алуга хокукларын тәэмин итү максатларында, шулай ук гражданнарның мөрәҗәгатьләрен кабул итү өчен "турыдан-туры элемтәләр" һәм "мөһим элемтәләр" эше оештырылырга мөмкин.

5.2. "Турыдан-туры элемтә" һәм "мөһим элемтә" телефоннары аша кабул ителгән мөрәҗәгатьләр "Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында" Федераль законда, "Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында" Татарстан Республикасы Законы һәм әлеге Тәртиптә билгеләнгән срокларда теркәлергә тиеш.

5.3.Гражданнарның "турыдан-туры линия" һәм "кайнар линия" телефоннары буенча мөрәҗәгатьләрен кабул итүгә вәкаләтле район Советының әйдәп баручы белгече, муниципаль район башлыгы ярдәмчесе гражданның мөрәҗәгатен терки һәм, мөрәҗәгать итүченең контакт телефонын һәм (яисә) электрон почта адресын (булган очракта), сорауның асылын, мөрәҗәгать кабул ителү датасын һәм вакытын күрсәтеп, мөрәҗәгатьнең электрон карточкасын (4 нче кушымта)булдыра.

5.4. Мөрәҗәгатьнең электрон карточкасындагы белешмәләр мөрәҗәгатьтә күтәрелгән сорауларны хәл итү компетенцияләренә керә торган тиешле органнарга җибәрелә.

5.5. "Турыдан-туры элемтәләр" һәм "мөһим элемтәләр" эше район Советы тарафыннан кабул ителә торган норматив хокукый актлар нигезендә гамәлгә ашырыла.

5.6. “Мөһим элемтәләр" телефоннары:
гомуми мәсьәләләр буенча - 8 (84368) 2-44-50, 8 (84368) 2-43-34
коррупциягә каршы көрәш мәсьәләләре буенча (84368) 2-44-76.

## 6. Коррупциячел юнәлештәге фактлар буенча гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау

6.1. Гражданнарның коррупциячел юнәлештәге фактлар буенча мөрәҗәгатьләре коррупция һәм янау, гражданнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен чикләү, хезмәт урынында үз-үзеңне тоту таләпләрен бозу, шулай ук вазыйфаи хәленнән явыз ниятләрдә файдалану билгеләре булган башка гамәлләр кылу фактлары турында белешмәләрне үз эченә ала.

6.2.Гражданнарның коррупциячел юнәлештәге фактлар буенча Район Советына кергән мөрәҗәгатьләре әлеге Тәртиптә билгеләнгәнчә каралырга тиеш.

6.3.Коррупциячел хокук бозулар турында мәгълүмат ачыкланган мөрәҗәгатьләр алдан карау процедурасын узганнан соң, кичекмәстән муниципаль район башлыгына яисә район башлыгы урынбасарына тапшырыла.

Муниципаль район башлыгы яки район башлыгы урынбасары резолюцияләр куялар һәм башкаручыларны билгелиләр. Мөрәҗәгатьне карау аерым контрольгә куела.

6.4.Коррупциячел юнәлештәге фактлар буенча гражданнарның мөрәҗәгатьләрен караганда мөрәҗәгать итүче ризалыгыннан башка мөрәҗәгатьтә булган мәгълүматларны, шулай ук гражданның шәхси тормышына кагылышлы белешмәләрне тарату тыела.

Мөрәҗәгатьтә күтәрелгән мәсьәләнең барлык очракларын ачыклауга кадәр компетенциясе кысаларында вазыйфаи затка язмача мөрәҗәгать җибәрү мөрәҗәгатьтәге мәгълүматларны ачуга керми.

6.5. Мөрәҗәгать карары яисә гамәле (гамәл кылмавы) мөрәҗәгать предметы булып торган дәүләт органына, җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка җибәрелә алмый.

6.6. Кергән мөрәҗәгатьтә хокукка каршы әзерләнә торган, кылына торган яисә кылынган гамәлләр турында, шулай ук аны әзерли, кыла һәм кылган зат хакында белешмәләр булганда, мондый мөрәҗәгать, теркәлә һәм компетенциясенә карап дәүләт органына җибәрелә.

6.7. Әгәр мөрәҗәгатьтә муниципаль хезмәткәрләргә муниципаль хезмәт белән бәйле бурычларны, чикләүләрне һәм тыюларны, шулай ук хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәмәү, муниципаль хезмәткәрнең шәхси кызыксынучанлыгы булуы, муниципаль хезмәткәрдә мәнфәгатьләр каршылыгы яки мәнфәгатьләр каршылыгының барлыкка килү мөмкинлеге турында, муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан башка коррупцион хокук бозулар мөмкинлеге турында белешмәләр бар икән, Балтач муниципаль районы башлыгы коррупцион һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча кадрлар хезмәте бүлегенең вазифаи затының (коррупцион һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы вазыйфаи затларның) язмача белдерүе нигезендә мөрәҗәгатьтә бәян ителгән фактларга карата тикшерү үткәрүнең максатка ярашлы булуы турында карар кабул итә.

Әлеге тикшерү хезмәт тәртибенә карата таләпләрнең үтәлешен тикшерү булып тора (муниципаль хезмәткәрләрнең чикләүләр һәм тыюларны мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яки җайга салу турында таләпләрне, 2008 елның 25 декабрендәге Федераль закон, № 273-ФЗ «Коррупциягә каршы көрәш турында» федераль закон һәм башка федераль законнар белән билгеләнгән бурычларны үтәвен) һәм Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва итүче гражданнар һәм муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан бирелә торган белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан хезмәт тәртибенә

карата таләпләрне үтәү турында " 2015 елның 2 февралендәге ПУ-71 номерлы Указы нигезендә үткәрелә.

6.8.Мөрәҗәгатьтә бәян ителгән фактлар оператив-эзләү чараларын үткәрү юлы белән тикшерүгә мохтаҗ булса, мөрәҗәгатьне карау барышында оператив-эзләү эшчәнлеген гамәлгә ашыруга вәкаләтле органнарга сорау җибәрелә.

6.9. Күрсәтелгән тикшерү барышында муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибе таләпләрен һәм (яки) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу таләпләрен үтәмәү турында таныклаучы фактлар ачыкланган очракта, Балтач муниципаль районы башлыгы тикшерү материалларын Балтач муниципаль районының муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү, муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның вазыйфаи тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча бердәм комиссиягә тапшыру турында карар кабул итә (алга таба - Комиссия).

Әлеге мәсьәләне комиссия утырышында карау турында карар кабул иткәндә утырышның датасы, вакыты һәм урыны билгеләнә, шулай ук комиссия утырышын норматив хокукый актлар нигезендә әзерләү эше оештырыла.

6.10. Мөрәҗәгать итүчегә мөрәҗәгатьтә куелган мәсьәләләрнең асылы буенча бирелгән җавапта үткәрелгән чаралар һәм тикшерүләр нәтиҗәләре, Комиссия карарлары (булганда) турында, шулай ук күрелгән чаралар турында, шул исәптән муниципаль хезмәткәргә җаваплылык чараларын куллану турында яисә тикшерү үткәрү өчен нигезләр булмавы һәм коррупция фактларының расланмавы турында мәгълүмат булырга тиеш.

6.11. Гражданнарның коррупциячел фактлар буенча мөрәҗәгатьләре белән эшләүче вазыйфаи затлар хезмәттәге мәгълүматның һәм конфиденциаль характердагы белешмәләрнең Россия Федерациясе законнары нигезендә сакланышы өчен билгеләнгән тәртиптә персональ җаваплылыкка ия була.

6.12.Гражданга мөрәҗәгатьтә куелган барлык сорауларга җавап җибәрелгәннән соң мөрәҗәгать контрольдән алына.

## 7. Гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү торышын тикшерү һәм аларның каралуын контрольдә тоту. Мөрәҗәгатьләрдә булган мәгълүматны анализлау һәм гомумиләштерү

7.1.Район Советының вазыйфаи затлары үз компетенциясе чикләрендә мөрәҗәгатьләрне карау тәртибен үтәүне контрольдә тота, гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләрнең эчтәлеген анализлый, гражданнарның хокукларын, ирекләрен һәм законлы мәнфәгатьләрен бозу сәбәпләрен үз вакытында ачыклау һәм бетерү буенча чаралар күрә.

7.2.Ай саен бердәм кабул итү көнен үткәрү буенча мәгълүматлар һәм гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү буенча статистик мәгълүматлар (5 нче кушымта) җыела.

7.3.Һәр яртыеллык нәтиҗәләре буенча гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә анализ ясала һәм аларны карап тикшерү үткәрелә. Әлеге анализ буенча хисап Балтач муниципаль районының Интернет мәгълүмати-

телекоммуникация челтәрендә http://baltasi.tatar.ru. адресы буенча рәсми сайтында урнаштырыла.

7.4.Район Советында авторга җавап бирергә яки тиешле органнар яки вазыйфаи затлар соравы буенча мәгълүмат бирергә кирәк булган барлык язма мөрәҗәгатьләрнең үтәлү вакыты контрольгә алына.

7.5.Мөрәҗәгатьләр белән эшләүнең торышы (кыскача мәгълүмати-статистик белешмәләр, мөрәҗәгатьләр белән эшне камилләштерү буенча үткәрелә торган чаралар һ.б.) район Советы эшчәнлеге турындагы еллык отчетларда һәм массакүләм мәгълүмат чараларында чагылдырыла.

## 8.Әлеге тәртипне бозган өчен җаваплылык

8.1.Әлеге Тәртипне бозуда гаепле затлар законнарда каралганча җаваплы булалар.

1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль район башлыгы тарафыннан гражданнарны шәхси кабул итүгә алдан язылу журналы**

| № п/п | Вакыт | Мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме | Регистрация адресы | Эш урыны/ элемтә өчен телефон | Мөрәҗәгатьнең кыскача эчтәлеге | Карап тикшерү нәтиҗәсе |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | |

2 нче кушымта

**Гражданнарны теркәү һәм кабул итү журналы**

| № кабул итү вакыты | Фамилиясе, исеме, атасының исеме, адресы | Кыскача эчтәлеге | Кемгә күчерелде | Үтәү өчен алу турында билге | Карау нәтиҗәләре |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |

3 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Балтач район Советы**

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы башлыгы тарафыннан гражданнарны шәхси кабул итүне исәпкә алу карточкасы**

№ ____ «____» _______20_ г.

Мөрәҗәгать итүченең ФИОсы_____________________________________________

Гариза бирүченең эш урыны һәм вазыйфасы_____________________________________________________________

Адрес__________________________________________________________________

Гаризаның кыскача эчтәлеге_____________________________________________

Алдагы мөрәҗәгать буенча нәрсә эшләнгән__________________________________________________________

Кабул итү алып баручының Ф. И. О сы

_____________________________________________________________________

Мөрәҗәгать итүченең имзасы__________________

Кемгә һәм нәрсә йөкләнгән, дата______________________________________________________________________

_____________________________________________________________________

Гаризаларны карау нәтиҗәләре______________________________________________________________

_____________________________________________________________________

Кайчан һәм кем җавап бирде-

_____________________________________________________________________

_____________________________________________________________________

Телдән җавап бирүгә риза_____________________________

4 нче кушымта

**"Турыдан-туры элемтә" һәм "мөһим линия" телефоннары буенча гражданнарның мөрәҗәгатьләрен кабул итү карточкасы**

№ Кабул итү датасы/вакыты _________________________________________

Адрес______________________________________________________________

Гражданинның ФИОсы_______________________________________________

Элемтә өчен телефон номеры_________________________________________

Электрон почта адресы______________________________________________

Яшәү
урыны_______________________________________________________________
___________________________________________________________________

Социаль хәле: Эш урыны ____________________________________________

Вазифа______________________________________________________________

Льготалы состав ________________________________________________

Мөрәҗәгать төре _________________________________________________

Кабатлык әйе соңгы мөрәҗәгатьнең датасы юк

Әңгәмә
эчтәлеге____________________________________________________________
____________________________________________________________________
________________________________________________________________

Башкаручы________________

Йөкләмә

Кабул итү нәтиҗәсе:

5 нче кушымта

1 нче табл.

Татарстан Республикасы Балтач район Советында гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү турында статистик мәгълүматлар

_______яртыеллык ____ел

| Орган атамасы | Барлыгы мөрәҗәгатьләр килде (хат һәм шәхси кабул итү) | | Электрон мөрәҗәгатьләр килде (Интернет, электрон почта) | | Шул исәптән җитәкчелеккә хәбәр ителде** | | Контрольгә алынды | | Уңай хәл ителде | | Урынга чыгу белән тикшерелде | | Граждан-нарны шәхси кабул итү | | Шул исәптән район башлыгы | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | алдагы ел | ел | алд. ел | ел | ел | алд. ел | ел | алд. ел | ел | ал д. ел | ел | алд. ел | ел | алд. ел | ел | алд. ел |
| | | | | | | | | | | | | | | | | |

2 нче табл.

Татарстан Республикасы Балтач район Советында гражданнарны бердәм кабул итү көнен үткәрү турында белешмә_____ ____ ел

| | | | Шул исәптән | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| № | Кабул итүләр саны | Кабул ителгән гражданнар саны | Район башлыгы тарафыннан | Район башлыгы урынбасары тарафыннан | Район Советы Аппараты җитәкчесе тарафыннан | Күчмә кабул итүләр саны |
| | | | | | | |